**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2019-2020 уку елы. 4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 57**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге калын сузык авазларның саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.* (Мәкаль)

а) 4;
ә) 8;
**б) 9;**
в) 10.

2. Аваз белән хәреф саны тигез булган сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *кульяулык*;**
ә) *юрган*;
б) *яфрак*;
в) *канәгать*.

3. Парсыз яңгырау тартыклар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [з], [җ];
**ә) [м], [н], [ң], [л], [р], [й], [w];**
б) [п], [ф], [к], [къ], [т], [ш], [с], [ч];
в) [ц], [щ], [һ], [х], [ʼ].

4. Сүз эчендә саңгырау тартыкның яңгыраулашкан очрагы күзәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *сүзе*;
ә) *таҗы*;
б) *флагы*;
**в) *тубы*.**

5. Антонимнар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *җәй, кыш*;**
ә) *кайнар, җылы*;

б) *боз, боз*;

в) *бала, сабый*.

6. Парлы сүз кулланылган мәкаль дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Балалы кеше – бай кеше.*

ә) *Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.*

**б) *Ата-бабалы кеше – тамырлы имән.***

в) *Һәр өйнең үз гадәте бар.*

7. Юнәлеш килешенең кушымчалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) -ның/-нең;

**ә) -га/-гә, -ка/-кә;**

б) -ны/-не;

в) -да/-дә, -та/-тә.

8. Ялгызлык исемнәрнең язылышы дөрес билгеләнгән рәтне күрсәтегез. **(2 балл)**

а) һәрвакыт куштырнаклар эченә алынып языла;

ә) җөмлә эчендә юл хәрефе белән языла;

б) җөмлә башында баш хәрефтән, җөмлә уртасында юл хәрефе белән языла;

**в) һәрвакыт баш хәрефтән языла.**

9. Фигыль күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *чикләвек*;

ә) *алтмыш*;

**б) *җырлый*;**

в) *ягымлы*.

10. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен* ***төзәтер***. (Мәкаль)

а) үткән заман хикәя фигыль;

**ә) киләчәк заман хикәя фигыль;**

б) хәзерге заман хикәя фигыль;

в) сыйфат.

**II. Башыгызны эшләтегез.**

Күпнокталар урынына **Е** яки **ЙО/ЙӨ** хәрефләрен куеп языгыз. **(14 балл)** (***йө****зтүбән,* ***йо****зак,* ***е****лга,* ***йо****мгак,* ***йо****тым,* ***е****шаю,* ***йө****герү,* ***йо****дрык,* ***йө****гереш,* ***йо****мшак,* ***е****гет,* ***йо****кы,* ***йо****мырка,* ***йө****зем,* ***е****герме,* ***йо****рт,* ***е****лау,* ***йо****лдыз,* ***е****л,* ***е****лан,* ***йө****кләмә,* ***е****фәк,* ***йо****мыш,* ***е****лкылдау,* ***йө****зек,* ***йо****ла,* ***е****лдам,* ***йө****з*).

**III.Теоретик бирем.**

Киләчәк заман хикәя фигыль турында языгыз, бер фигыльне зат-сан белән төрләндерегез. **(8 балл)**

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Табышмакны укыгыз, җавабын языгыз. **(2 балл)** **<u>(туп)</u>**
2. ***Биек*** сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. **(3 балл)**
3. Сез нинди уен уйнарга яратасыз? Уенның тәртибен аңлатып, 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. (**10 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының**
**муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2019-2020 уку елы. 5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 57**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. *Шигырь* сүзенә дөрес транскрипция ясалган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) [*шигырь*];

ә) [*шигыр*];

б) [*шигъыр*];

**в) [*шигъэр*].**

2. Калын пары булмаган аваз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) [э];

**ә) [и];**

б) [ң];

в) [һ].

3. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Зөһрә кызның бик озын кара чәч толымнары очында авыр-авыр чулпылары асылынып торалар.* (Фатих Әмирхан)

а) 2;

**ә) 3;**

б) 4;

в) 5.

4. Җөмләдәге антонимнарның барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Аз сүз – алтын, күп сүз – бакыр.* (Мәкаль)

а) *аз – күп*;

ә) *алтын – бакыр*;

**б) *аз – күп, алтын – бакыр*;**

в) *аз – күп, сүз – сүз, алтын – бакыр*.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Балыкчылар*** *ломнар, балталар эләктерәләр дә тизрәк* ***балыкларны*** *коткарырга ашыгалар.* (Николай Сладков)

**а) тамырдаш сүзләр;**

ә) синонимнар;

б) искергән сүзләр;

в) омонимнар.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Авызың кыек булса, көзгегә* ***үпкәләмә***. (Мәкаль)

а) үткән заман хикәя фигыль;

ә) хәзерге заман хикәя фигыль;

б) киләчәк заман хикәя фигыль;

**в) боерык фигыль.**

7. Җөмләдәге сыйфатның дәрәҗәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Күк йөзе зәңгәрсу булып калды.* (Дания Гайнетдинова)

а) гади дәрәҗә;

ә) чагыштыру дәрәҗәсе;

б) артыклык дәрәҗәсе;

**в) кимлек дәрәҗәсе.**

8. Җөмләдәге саналмышларның барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Искәндәр, сигезенче көнне кулына бер кылыч тотып, тимерче бинасыннан чыкты.* (Шәһит Әхмәдиев)

а) *көнне*;

ә) *кылыч*;

**б) *көнне, кылыч*;**

в) *сигезенче, бер*.

9. Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Кояшкаем****, чык, чык!*

*Ялындырма, көттермә,*

*Безнең янга ашык!* (Галимҗан Гыйльманов)

**а) эндәш сүз;**

ә) ия;

б) хәбәр;

в) аергыч.

10. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Беркөнне Мәфтуха әбигә шәһәрдән оныгы кунакка кайткан.* (Роза Хафизова)

а) *Мәфтуха*;

ә) *әбигә*;

б) *Мәфтуха әбигә*;

**в) *оныгы*.**

## II. Башыгызны эшләтегез.

1. Күпнокталар урынына **Н** яки **Ң** хәрефләрен куеп языгыз. **(7 балл)**

*уры**н**га, я**ң**адан, боры**н**гы, салы**н**кы, и**ң**емдә, муе**н**га, басы**н**кы, я**ң**арыш, ты**н**гысыз, кие**н**гән, иртә**н**ге, кабары**н**кы, я**ң**абаштан, күтәре**н**ке.*

2. Тамырында **Ң** хәрефе булган 10 сүз уйлап языгыз. **(5 балл)**

<u>Мәсәлән:</u> *таң, миң, дуңгыз, яңак, аң, маңгай, тиң, уң, уңыш, чаң*

## III. Теоретик бирем.

Тиңдәш кисәкләр турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. **(8 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Табышмакның төшеп калган хәрефләрен куеп, күчереп языгыз. **(5 балл)**

*Ая**г**ын-башын кистем,*

*К**о**рсагын **т**иштем,*

*Эченә өрдем,*

*Моңайганын белдем.*

2. Җавабын табыгыз. **(2 балл) (курай)**

3. Яңа ел кичәсендә сез нинди чыгыш ясар идегез? Концертлар куйганда, сез нинди номер башкара аласыз? Шул хакта 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. (**10 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ 2019-2020 уку елы. 6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 62**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Хәрефләргә караганда авазлар саны кимрәк булган сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *юкә*;

ә) *көньяк*;

**б) *мәгънә*;**

в) *күренеш*.

2. Җөмләдәге ябык иҗекләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.* (Мәкаль)

а) 4;

ә) 5;

б) 6;

**в) 7.**

3. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Авылдаш, картларча, биюче, кайткансыз, беркайчан, мәңге, бардык, ләкин, эшләпә, укыгыз.*

а) 4;

ә) 5;

**б) 6;**

в) 7.

4. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәреше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бөркетнең канаты* ***очканда*** *ныгый.* (Мәкаль)

**а) яңгыраулыкта охшашлану;**

ә) саңгыраулыкта охшашлану;

б) тел арты ассимиляциясе;

в) ирен ассимиляциясе.

5. Сүзләрнең кулланылыш өлкәсе ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кәй, берсәк, бак, ихата, пецән.*

а) һөнәрчелек сүзләре;

**ә) диалекталь сүзләр;**

б) терминнар;

в) жаргоннар.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ә бездә* ***дуслар*** *бар,* ***дошман*** *бар.* (Мөдәррис Әгъләмов)

**а) антонимнар;**

ә) синонимнар;

б) омонимнар;

в) күчерелмә мәгънәле сүзләр.

7. Сүзләрнең кайсы телдән алынганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Вәгъдә, хушбуй, рәссам, сәнгать, дус, хат, фигыль*.

а) рус;

ә) француз;

б) итальян;

**в) гарәп-фарсы.**

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кичен бака* ***кычкырса****, көн җылы булыр.* (Сынамыш)

**а) шарт фигыль;**

ә) хәзерге заман хикәя фигыль;

б) киләчәк заман хикәя фигыль;

в) үткән заман хикәя фигыль.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең нинди җөмлә кисәге булуы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Зәңгәр*** *күктә* ***ак*** *болыт йөзә иде.* (Фәрит Яхин)

а) ияләр;

**ә) аергычлар;**

б) хәбәрләр;

в) тәмамлыклар.

10. Тиңдәш кисәкләр кулланылган җөмлә дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Юләргә акыл кирәкми.* (Мәкаль)

ә) *Аю – көченә, кеше акылына ышана.* (Мәкаль)

**б)** ***Ир-егет өйдә туар, яуда үләр.*** **(Мәкаль)**

в) *Намусың үз кулыңда.* (Мәкаль)

## II. Башыгызны эшләтегез.

Күпнокталар урынына **НГ/ҢГ/Ң/Н** хәрефләрен куеп языгыз. **(10 балл)**

*у**ң**айсызлану, ма**ңг**ай, ә**ңг**әмә, са**ңг**ырау, чө**н**ки, чо**ңг**ыл, со**ң**ыннан, у**ң**ган, ди**ңг**ез, ты**нг**ысыз, ча**ңг**ычы, ма**ң**корт, кү**ң**ел, и**ң**күлек, өя**н**ке, я**ңг**ыр, та**ңг**ача, өрә**ңг**е, түбә**нг**е, сө**ңг**е.*

## III. Теоретик бирем.

Исем сүз төркеме турында белгәннәрегезне языгыз. **(8 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Төшеп калган хәрефләрне куеп, шигырьне күчереп языгыз. **(5 балл)**

*Тегүчеләр*

*К**ы**ш болы**н**га юрган с**ы**рган.*

*Ту**ң**масын дип калын иткән.*

*Ә куян**н**ар юрган читен*

*Тигез итеп тегеп киткән.*

(Рафис Корбан)

2. ***Болынга*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(5 балл)**

3. Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(4 балл)**

*Кыш – **җәй**, калын – **юка**, тигез – **кәкре**, тегеп – **сүтеп**.*

4. Кышкы табигатьне сурәтләп, 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. (**10 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының**
**муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2019-2020 уку елы. 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 59**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Хәрефләргә караганда авазлар саны кимрәк булган сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *нәкъ*;**

ә) *көньяк*;

б) *яшь*;

в) *һәркем*.

2. Тартыкларның чиратлашуы күзәтелгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Үзенең йомшаклыгын таныган кеше көчле кешегә әверелә.* (Оноре де Бальзак)

а) *йомшаклыгын, таныган, кешегә*;

ә) *йомшаклыгын, таныган*;

б) *йомшаклыгын, кешегә*;

**в) *йомшаклыгын*.**

3. Басымы өченче иҗеккә төшә торган сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *укыдылар*;

ә) *бернинди*;

**б) *сабыйларча*;**

в) *игътибарлы*.

4. Сүзләрнең кайсы төргә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Гипс, шприц, катаракта, ангина, бинт, диабет*.

а) күчерелмә мәгънәле сүзләр;

**ә) терминнар;**

б) синонимнар;

в) диалекталь сүзләр.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Аръяк яр һәрвакыт ямьлерәк күренә.* (Мәкаль)

**а) *аръяк, һәрвакыт, ямьлерәк*;**

ә) *аръяк, һәрвакыт*;

б) *аръяк, ямьлерәк*;

в) *аръяк, һәрвакыт, ямьлерәк, күренә*.

6. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Тирән күлдә балык та **күбрәк**.* (Мәкаль)

а) сыйфат;

**ә) рәвеш;**

б) хикәя фигыль;

в) боерык фигыль.

7. Җөмләдәге артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Чәчәкнең күксел-зәңгәр, аксыл-зәңгәр, аксыл-саргылт, сап-сары төрткеләре, кып-кызыл җепселләре бар.* (Рафаил Төхфәтуллин)

а) *күксел-зәңгәр, аксыл-зәңгәр, аксыл-саргылт, сап-сары, кып-кызыл*;

ә) *зәңгәр, зәңгәр, саргылт, сап-сары, кып-кызыл*;

б) *күксел, аксыл, аксыл*;

**в) *сап-сары, кып-кызыл*.**

8. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Әгәр боз өстендә боз катса, ашлык яхшы уңар.* (Сынамыш)

а) теркәгеч, исем, бәйлек, исем, шарт фигыль, исем, сыйфат, хикәя фигыль;

**ә) теркәгеч, исем, бәйлек сүз, исем, шарт фигыль, исем, сыйфат, хикәя фигыль;**

б) кисәкчә, исем, бәйлек сүз, исем, шарт фигыль, исем, сыйфат, хикәя фигыль;

в) теркәгеч, исем, бәйлек сүз, исем, шарт фигыль, исем, рәвеш, хикәя фигыль.

9. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Нуриасма Маратны җиде мәртәбә Ык буена алып төшеп, таң суы белән юындырды, таң суы эчерде.* (Фоат Садриев)

**а) *Нуриасма*;**

ә) *Маратны*;

б) *Ык*;

в) *таң*.

10. Җәенке җөмлә дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Кыюлык – бәхет.* (Мәкаль)

ә) *Бүләк зур булмас.* (Мәкаль)

б) *Халык картаймый.* (Мәкаль)

**в) *Хәрәкәттә бәрәкәт.* (Мәкаль)**

## II. Башыгызны эшләтегез.

Күпнокталар урынына **Х** һәм **Һ** хәрефләрен куеп языгыз. **(10 балл)**

*Мә**х**шәр, **һ**авалану, **х**орафат, ка**һ**арман, фә**һ**ем, **х**әрабә, тәсби**х**, али**һ**ә, **х**өрәсән, мөҗа**һ**ид, кә**һ**вә, ша**һ**задә, **х**ирыс, мә**х**шәр, и**х**ата, мә**х**рүм, фати**х**а, мә**х**кәмә, я**һ**үди, мәз**һ**әб.*

## III. Теоретик бирем.

Уңай ассимиляция турында белгәннәрегезне языгыз. **(8 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Һиндстанда туган Акрит Йасуал – иң яшь табиб. Биш яшьтә ул инде анатомияне су урынына эчә, Шекспир әсәрләрен яратып укый. Җиде яшендә җирле хастаханәдә беренче операциясен ясый.* (Календарьдан)

1. ***Җирле*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(3 балл)**
2. ***Туган, операциясен*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл)**
3. ***Су урынына эчә***, ***беренче*** сүзләренең синонимнарын уйлап языгыз. **(2 балл)** ***(бик әйбәт белә, тәүге)***
4. Сез нәрсәгә сәләтле, нинди эшне бик әйбәт һәм яратып башкарасыз? Шул хакта 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(10 балл)**

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ 2019-2020 уку елы. 8 нче сыйныф

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 66**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Безнең кадеребезне, матурлыгыбызны беләсең килсә, Аю агай, син бөек шагыйрь Г.Тукай шигырьләрен тыңлап кара һәм илебезнең олы рәссамы И.Шишкин картиналарына күз сал.* (Гариф Галиев)

а) 2;

**ә) 3;**

б) 4;

в) 5.

2. Җөмләдәге ТСТ (тартык+сузык) иҗек калыбының саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Күзләрен кояш нурлары иркәләүдән уянып китте ул.* (Фәрит Яхин)

а) 6;

ә) 7;

**б) 8;**

в) 9.

3. Бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Имана, айбалта, тархан, вәзир.***

а) неологизмнар;

**ә) тарихи сүзләр;**

б) архаизмнар;

в) актив сүзләр.

4. Җөмләдәге антонимнарның барысы да күрсәтелгән дөрес рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә.* (Габдулла Тукай)

а) *бүген – иртәгә*;

ә) *бай – ярлы*;

**б) *бүген – иртәгә, бай – ярлы*;**

в) *син – шайтан, бүген – иртәгә, бай – ярлы*.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Йомгактай бер көчек агачлардагы үзгәрешләрне тикшерә һәм шатлыгыннан өреп куя.* (Рөстәм Зарипов)

**а) *йомгактай, агачлардагы, үзгәрешләрне, шатлыгыннан*;**

ә) *йомгактай, шатлыгыннан*;

б) *йомгактай, үзгәрешләрне, шатлыгыннан*;

в) *йомгактай, көчек, агачлардагы, үзгәрешләрне, тикшерә, шатлыгыннан, өреп*.

6. Җөмләдәге фигыльләрнең төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Урамга чыксаң, зәмһәрир суык сулышны каплый, борын эчен әчеттерә, бияләй эченә кереп, бармакларны саный.* (Туфан Миңнуллин)

а) сыйфат фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль, хәл фигыль, хикәя фигыль;

ә) шарт фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль;

б) хәл фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль, хәл фигыль, хикәя фигыль;

**в) шарт фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыль, хәл фигыль, хикәя фигыль.**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Агач кәүсәсе* ***буйлап*** *аска төшә* ***дә*** *коры* ***һәм*** *йомшак мүк алып, тиз* ***генә*** *өскә йөгерә.* (Гарәфи Хәсәнов)

а) бәйлек, җыючы теркәгеч, җыючы теркәгеч, чикләүне белдерә торган кисәкчә;

**ә) бәйлек сүз, җыючы теркәгеч, җыючы теркәгеч, чикләүне белдерә торган кисәкчә;**

б) бәйлек сүз, көчәйтүне белдерә торган кисәкчә, җыючы теркәгеч, чикләүне белдерә торган кисәкчә;

в) бәйлек сүз, җыючы теркәгеч, җыючы теркәгеч, көчәйтүне белдерә торган кисәкчә.

8. Күпнокталар урынына куелырга тиешле тыныш билгесе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкау бер эш эшли белә (**...**) чалкан ятып мышный белә.* (Мәкаль)

**а) ике нокта;**

ә) сызык;

б) өтер;

в) нокталы өтер.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ул алма **шундый** матур, **шундый** тәмле һәм хуш исле!* (Идрис Туктар)

а) урын хәле;

ә) аергыч;

**б) күләм хәле;**

в) рәвеш хәле.

10. Җөмләнең баш кисәкләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

***Иртәгә нәрсә эшлисен белмәгән кеше – иң бәхетсез кеше.*** (Максим Горький)

а) *Кеше – кеше*;

ә) *Белмәгән кеше – кеше*;

**б) *Кеше – иң бәхетсез кеше*;**

в) *Кеше – иң бәхетсез*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җәяләрне ачып, кушма, парлы һәм тезмә сүзләрне дөрес итеп языгыз. **(10 балл)**

*Өч (аяк), өченче (көн), ярым (утрау), ярым (бокҗра), ярым (йорты), ярым (шар), ярым (үткәргеч), ярты (килограмм), ярты (еллык), ярты (гасыр), ярты (йорты), ярты (акыл), ярты (сәгать), әйләнә (тирә), ярым*

*(финал), әйлән (бәйлән), биш (урынлы), премьер (министр), биш (еллык), биш (былтыр).*

**Өчаяк, өченчекөн, ярымутрау, ярым божра, ярым-йорты, ярымшар, ярымүткәргеч, ярты килограмм, ярты еллык, ярты гасыр, ярты-йорты, ярты акыл, ярты сәгать, әйләнә-тирә, ярымфинал, әйлән-бәйлән, бишурынлы, премьер-министр, бишьеллык, бишбылтыр.**

## III. Теоретик бирем.

Кире ассимиляция турында аңлатыгыз, фикерегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. **(8 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Татар халкы нинди авыр заманнарда гына яшәмәсен, Китабын һәм Язуын саклап кала алган!* (Миркасыйм Госман)

1. ***Авыр*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(3 балл)**

2. ***Китап*** сүзеннән башланган 5 мәкаль уйлап языгыз. **(5 балл)**

Мәсәлән: (*Китап – белем чишмәсе. Китап – галим, телсез мөгаллим. Китапның белмәгәне юк. Китапсыз өй – ишәк абзары. Китапсыз өй – тәрәзәсез бүлмә. Китап – тормыш көзгесе.*)

3. ***Үз-үзеңне, өчен*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл)**

4. ***Нинди, яшәмәсен, Китабын, саклап кала алган*** сүзләренең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(4 балл)**

*Нинди* – күләм хәле, *яшәмәсен* – кире хәл, *Китабын* – туры тәмамлык, *саклап кала алган* – кушма фигыль хәбәр.

5. Сезнең “Татарча диктант” акциясен ишеткәнегез бармы? Ул кайчан һәм нинди максат белән уздырыла? Шул хактагы фикерләрегезне 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(10 балл)**

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ

**2019-2020 уку елы. 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Йоткылык тартыгы кулланылган сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *даһи*;**

ә) *яхшылык*;

б) *таң*;

в) *маэмай*.

2. Басым соңгы иҗеккә төшми торган сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *куштырнак*, *өтер*, *сызык*, *нокта*;

ә) *анда*, *сөйли*, *акчалата*, *аксыл*;

**б) *ягъни*, *һәркем*, *русча*, *язабыз*;**

в) *җәен*, *сөйкемле*, *туганлык*, *йоклаганнар*.

3. Бирелгән омонимнарның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Без – кешеләр...*
*Адәм баласында*
*Булмый кала алмый хаталар.*

*Бар ялгышлар –*
*Киләчәккә юллап*
*Барып җитә алган хат алар.*

(Рифат Сәлах)

а) саф омонимнар;

**ә) омофоннар;**

б) омографлар;

в) омоформалар.

4. Шигъри юллардагы калын хәрефләр белән бирелгән архаизмның хәзерге әдәби телдәге варианты дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Гәүһәрне таш дию белән ул таш булмас,*

***Тикмә** кеше гәүһәр кадрен белә алмас.* (Кол Гали)

а) *ләкин*;

ә) *тик*;

**б) *һәрбер*;**

в) *һичбер*.

5. Шигъри юлларда кулланылган сыйфатларның барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Карлар яуган. Җир төренгән*

*Ак мамык юрганына.*

*Шатланам мамык карларга,*

*Сөенәм матур кышка.* (Гөлнур Корбанова)

а) *ак*;

**ә) *ак, матур*;**

б) *матур*;

в) *ак, мамык, мамык, матур*.

6. Җөмләдәге сүз төркемнәре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Җир астыннан йөргән еланны да сизәләр.* (Мәкаль)

**а) исем, бәйлек сүз, сыйфат фигыль, исем, кисәкчә, хикәя фигыль;**

ә) исем, бәйлек, сыйфат фигыль, исем, кисәкчә, хикәя фигыль;

б) исем, бәйлек, хикәя фигыль, исем, кисәкчә, хикәя фигыль;

в) исем, бәйлек сүз, сыйфат фигыль, исем, теркәгеч, хикәя фигыль.

7. Җөмләдәге хәбәр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Нәрсә соң ул батырлык?* (Фәнис Яруллин)

а) *батырлык*;

ә) *ул*;

б) *нәрсә соң*;

**в) *нәрсә соң ул*.**

8. Дания Гайнетдинова иҗатыннан алынган җөмләдә дөрес тыныш билгеләре куелган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *Журналның безгә очкыч (самолёт) ясарга өйрәткән бүлеге ошады.***

ә) *Журналның безгә очкыч, самолёт, ясарга өйрәткән бүлеге ошады.*

б) *Журналның безгә очкыч – самолёт – ясарга өйрәткән бүлеге ошады.*

в) *Журналның безгә очкыч – самолёт ясарга өйрәткән бүлеге ошады.*

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Салган саен, кармакка балык эләкми*. (Мәкаль)

а) синтетик иярчен вакыт җөмлә;

ә) аналитик иярчен вакыт җөмлә;

**б) синтетик иярчен күләм җөмлә;**

в) синтетик иярчен урын җөмлә.

10. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Күз алдына китерегез: көзге бакча сукмагында бозга укмашып каткан яшел яфраклар...* (Галимҗан Гыйльманов)

**а) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә;**

ә) аналитик иярчен шарт җөмлә;

б) аналитик иярчен урын җөмлә;

в) синтетик иярчен урын җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Бирелгән диалекталь сүзләрнең әдәби телдәге вариантларын языгыз. **(10 балл)**

*Ызба – өй, нүгез – мөгез, алҗапма – алъяпкыч, үмит – эскерт, ылан – бала, ындыр – бакча, кычык – эт, ләкилә – токмач, күгеләк – бөрлегән, йан күү – сусау.*

**III. Теоретик бирем.**

Җөмләнең баш кисәкләре турында белгәннәрегезне языгыз. **(8 балл)**

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

*Табиблар дәваламас авыруын наданның,*
*Дәвала белем белән наданлыгын аның.*

(Йосыф Баласагунлы)

1. ***Дәвала*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(3 балл)**

2. ***Надан*** сүзеннән башланган 5 мәкаль уйлап языгыз. **(5 балл)**

**<u>Мәсәлән:</u>** *Надан кеше – сукыр тавык. Наданга тик тору җавап. Надан белмәсә дә кычкыра. Наданлыкка ишәк кенә түзә. Наданлык оят түгел, укымау оят.*

3. ***Дәваламас, аның*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл)**

4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(6 балл)** ***(теркәгечсез тезмә кушма җөмлә)***

5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2019-2020 уку елы. 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге рәт гармониясенә бусынган сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ит ашадың – дәрт алдың, шулпа ашадың – шифа алдың.* (Мәкаль)

а) 8;

ә) 7;

б) 6;

**в) 5.**

2. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәреше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Иренгән*** *ике эшләгән, һаман эше пешмәгән.* (Мәкаль)

а) борын ассимиляциясе;

ә) ирен ассимиляциясе;

**б) тел арты ассимиляциясе;**

в) саңгыраулыкта охшашлануның кире төре.

3. Шигырьдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бердәм бергәлек булмаса,*

*Олы ил дә* ***таркала****.*

*Бүгенгесе мескенләнә,*

*Киләчәге* ***тар кала****.* (Шәүкәт Галиев)

а) синонимнар;

ә) күп мәгънәле сүзләр;

**б) омофоннар;**

в) омоформалар.

4. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кичләрен бөтен йорт симфония белән тула: бер яктан* ***Бетховен****, астан* ***Сен-Санс****, форточкадан* ***Чайковский*** *ишетелә.* (Мөхәммәт Мәһдиев)

а) метафора;

**ә) метонимия;**

б) синекдоха;

в) синоним.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Һы****, әллә мин аңгырамы, шуны белмәскә?!* (Фәнис Яруллин)

а) кисәкчә;

ә) модаль сүз;

**б) ымлык;**

в) аваз ияртеме.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Эшчән кеше булу бик зур бәхет,*

*Эш* ***ул*** *бу тормышның үзәге.* (Мәҗит Гафури)

а) күрсәтү алмашлыгы;

ә) билгеләү алмашлыгы;

б) зат алмашлыгы;

**в) кисәкчә.**

7. Җөмләдәге фигыль формалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ташларны күчерә-күчерә, шәһәрләр төзесәң, җимеш-гөлләр үстерсәң баерсың.* (Мөхәммәт Мирза)

**а) хәл фигыль, шарт фигыль, шарт фигыль, хикәя фигыль;**

ә) хәл фигыль, шарт фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль;

б) хикәя фигыль, шарт фигыль, шарт фигыль, хикәя фигыль;

в) хәл фигыль, сыйфат фигыль, сыйфат фигыль, хикәя фигыль.

8. Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Күз яше җиргә* ***тамса да*** *кипми.* (Мәкаль)

а) шарт хәле;

**ә) кире шарт хәле;**

б) сәбәп хәле;

в) хәбәр.

9. Күпнокталар урынына куелырга тиешле тыныш билгесе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кызыл һәм сарылар, ак һәм кара чәчкәләр* ***(...)*** *һәммәсе дә күзнең явын ала торганнар.* (Гарәфи Хәсәнов)

а) өтер;

ә) нокталы өтер;

**б) сызык;**

в) ике нокта.

10. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Этләр тимәсен дип, кыз бала бабайны капкага чаклы озата чыкты.* (Шәһит Әхмәдиев)

а) синтетик иярчен сәбәп җөмлә;

**ә) синтетик иярчен максат җөмлә;**

б) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә;

в) синтетик иярчен шарт җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Бирелгән искергән сүзләрнең әдәби телдәге вариантларын языгыз. **(10 балл)**

*Тыйб – медицина, җәгърәфия – география, Мажарстан – Венгрия, динар – алтын акча, шималь – Төньяк, инкыйраз – юкка чыгу, ислах – реформа, голүм – белем, җәнүб – Көньяк, дәрелфөнүн – университет.*

## III. Теоретик бирем.

Сингармонизм законы турында белгәннәрегезне языгыз. **(8 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Шуны әйтергә кирәк* ***(...)*** *үз-үзеңне тәрбияләү бирәүгә дә җиңел түгел. Моның өчен теләк, тырышлык, ныклы ихтыяр көче, гаделлек һәм матурлыкка даими омтылыш кирәк.* (Фаек Мөхәммәтҗанов)

1. Күп нокталар урынына тиешле тыныш билгесен куегыз. **(1 балл)**
2. ***Гаделлек*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(3 балл)**
3. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне языгыз. **(2 балл)** (**<u>ихтыяр, даими)</u>**
4. ***Үз-үзеңне, өчен*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл) (үз-үзеңне – билгеләү алмашлыгы, исемне алыштырып килгән төшем килешенә тартым белән төрләнгән берлек санда; өчен – иялек килешен таләп итүче бәйлек)**
5. Беренче җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(6 балл)** ***(иярченле кушма җөмлә)1 – баш компонент, 1 – аналитик иярчен тәмамлык җөмлә***
6. Сез ничек уйлыйсыз: кеше үз-үзен тәрбияли аламы? Шул хактагы фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ

## 2019-2020 уку елы. 11 нче сыйныф

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 77**

### I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге калын сузык авазларның саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Дөньяда иң кечкенә бәхет – байлык, иң зур бәхет – саулык.* (Мәкаль)

а) 6;

**ә) 7;**

б) 8;

в) 9.

2. Сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Дөядәй буең булганчы, төймәдәй акылың булсын.* (Мәкаль)

а) *булганчы*;

ә) *дөядәй, төймәдәй*;

**б) *дөядәй, булганчы, төймәдәй*;**

в) *дөядәй, булганчы, төймәдәй, булсын*.

3. Архаизм дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *санак*;

ә) *кучат*;

б) *ярлык*;

**в) *углым*.**

4. Телара сүзлек дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) “Татарча-русча сүзлек”;**

ә) “Татар исемнәре сүзлеге”;

б) “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”;

в) “Татар теленең орфографик сүзлеге”.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Алтын **җем** итә, табынганны җен итә.* (Мәкаль)

а) исем;

ә) фигыль;

**б) аваз ияртеме;**

в) ымлык.

6. Һәрвакыт сүз артыннан килә торган кисәкчәләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *түгел, бит, ләбаса, -мыни*;**

ә) *нәкъ, дөм, сап-, һич*;

б) *җете, иң, тома, бик*;

в) *һәм, әллә, әмма, чөнки*.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Ул** урманда яшел киемле агачлар үсәләр, тәмле-тәмле җиләкләр кызарып пешәләр.* (Абдулла Алиш)

а) зат алмашлыгы;

**ә) күрсәтү алмашлыгы;**

б) билгеләү алмашлыгы;

в) кисәкчә.

8. Җөмләдәге барлык хәбәрләр дә дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Күпне күр дә фикер ит, юкны күр дә шөкер ит.* (Мәкаль)

а) *фикер ит, шөкер ит*;

ә) *ит, ит*;

б) *күр, ит, күр, ит*;

**в) *күр, фикер ит, күр, шөкер ит*.**

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кемнең җырын җырласаң, шуның көен көйләрсең*. (Мәкаль)

а) синтетик иярчен шарт җөмлә;

**ә) аналитик иярчен аергыч җөмлә;**

б) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә;

в) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә.

10. Бирелгән җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Чәчәкләрне кемнәр өзә, кемнәр шундый сихри матурлыкка кул күтәрә – Гәүһәр белми.* (Халисә Ширмән)

а) иярченле кушма җөмлә;

ә) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;

**б) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;**

в) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Шакмакларга тиешле хәрефләрне куеп, гарәп-фарсы алынмаларын языгыз **(10 балл)**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| м | ә | х | ә | **б** | **б** | ә | т |
| т | ә | к | ә | **б** | **б** | е | р |
| м | ө | к | и | **б** | **б** | ә | н |
| м | ө | к | а | **д** | **д** | ә | с |
| т | ә | в | ә | **к** | **к** | ә | л |
| т | ә | х | ә | **л** | **л** | ү | с |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| м | ө | г | а | **л** | **л** | и | м |
| җ | ә | һ | ә | **н** | **н** | ә | м |
| м | ө | д | ә | **р** | **р** | и | с |
| м | ө | х | ә | **р** | **р** | и | р |

## III. Теоретик бирем.

Тәмамлык турында белгәннәрегезне языгыз. **(8 балл)**

## IV. Гамәли һәм иҗади бирем.

*“Сугыш” сүзен ишеткәч, ялгыз алмагач күз алдыма килә: түбәндә җил койган яшел алмалар...* (Шәүкәт Галиев)

1. Уңай ассимиляция чагылыш тапкан сүзләрне сайлап языгыз. Алар уңай ассимиляциянең кайсы төренә карыйлар? **(5 балл)**

***(Ишеткәч, алдыма, төбендә, койган – яңгыраулыкта-саңгыраулыкта охшашлану)***

2. ***Сугыш*** сүзенең синонимик оясын һәм антонимнарын языгыз. **(4 балл)**

3. ***Сугыш*** һәм ***алмагач*** сүзләрен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, сүз төзелеше ягыннан тикшерегез. **(6 балл)**

4. ***Ишеткәч***, ***койган*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл)**

5. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(6 балл)** (***берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә***)

6. Сугышның фаҗигасе, аны булдырмау юллары, сугыш һәм тынычлык белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**